ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

№2 21.11.2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районы Кәкре Елга авыл җирлегенә керүче
Якты Юл авылында 2020 елда үзара салым
җыюны кертү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законынын 35 статьясы нигезендә, "2020 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Якты Юлавылында халык җыены карар бирә:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең Якты Юлторак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400,00 (дүрт йөз) сум күләмендә, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум күләмендә түләүне киметергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:
- Якты Юл бистәсендә су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү) ;
- Якты Юл бистәсендә юлларны кардан чистарту (килешү буенча эш өчен түләү);
- Якты Юл бистәсе территориясен җәйге вакытта чабып алу (килешү буенча эшләр өчен түләү, запас частьләр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу) турындагы карары кабул ителде.

3. Әлеге халык җыены карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: : http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Якты Юл авылы, Яна Юл ур., 15 йорт адреслары буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Кәкре Елга авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Кәкре Елга авыл җирлеге башлыгы: И.М.Мухаметзянов